**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Иске Маврин авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**25.09.2026** **№27**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларның үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу әһәмиятле булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында Карар кабул итү тәртибе хакында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнар, «Керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти хакимиятнең йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру тәртибе хакында" 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы, "Муниципаль вазыйфаны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе хакында" 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советы

**Карар итте:**

1.Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының, керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти

характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу әһәмиятле булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында Карар кабул итү тәртибен расларга (кушымта).

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге Советының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

- 2020 елның 05 августындагы 187 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу әһәмиятле булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында Карар кабул итү тәртибе хакында ";

- 2023 елның 19 апреленнән 99 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советының 2020 елның 05 августындагы 170 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу әһәмиятле булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында Карар кабул итү тәртибе хакында"

3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына җаваплылык чарасын куллану турындагы карар белән танышу яисә мондый карар турында хәбәр итү мөмкин түгеллеге хакында карар белән танышудан баш тарту турындагы акт төзүгә (килешү буенча) вәкаләт бирергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында" бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Нургалеев**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советы карарына кушымта
25.09.2026 ел № 27

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу әхәмиятле булмаса, җаваплылык чаралары турында Карар кабул итү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу әһәмиятле булмаса, җаваплылык чаралары (алга таба - җаваплылык чаралары) куллану турында Карар кабул итү процедурасын регламентлаштыра.

2. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга карата «гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 4 өлешендә санап үтелгән җаваплылык чараларының берсен куллану турындагы мәсьәлә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге Советында (алга таба - Совет) карала.

Күрсәтелгән мәсьәләне карау өчен нигез булып Советка Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) «Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясындагы 7.2 өлешендә каралган муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану турында гаризасы тора.

3. Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасы Совет тарафыннан ул кергән көннән өч айдан да соңга калмыйча карала.

4. Совет муниципаль вазыйфаны биләүче затка күрсәтелгән мәсьәләне карау датасына кимендә биш эш көне кала язма рәвештә аңа карата җаваплылык чаралары куллану турындагы мәсьәләне карау турында хәбәр итә.

Муниципаль вазыйфаны биләүче затның Совет утырышы урыны һәм вакыты турында хәбәр ителгәч килмәве Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасын карарга комачауламый.

5. Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чаралары куллану турындагы гаризасы Совет утырышында "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге Советы Регламенты турында" Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге Советының 28.12.2005 ел, № 10 карары белән расланган Совет регламентында (алга таба - регламент) билгеләнгән тәртиптә карала.

Күрсәтелгән мәсьәлә каралганда муниципаль вазыйфаны биләүче затка тапшырылган белешмәләр буенча аңлатма бирү мөмкинлеге бирелергә тиеш.

Муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларының берсен куллану турындагы мәсьәләне караганда, депутатлар мәнфәгатьләр конфликтын кисәтү һәм җайга салу таләпләрен үтәргә тиеш. Совет утырышында рәислек итүче депутатларга мәнфәгатьләр конфликты булу-булмавы турында хәбәр итәргә тәкъдим итәргә тиеш.

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу максатларында мәнфәгатьләр конфликтының ягы булган депутат рәислек итүче тарафыннан карар кабул итүдән читләштерелә.

6. Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) гаризасын карау нәтиҗәләре буенча муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чарасын куллану турында яки җаваплылык чарасын куллануда баш тарту турында Карар кабул ителә.

Күрсәтелгән карар Регламентта билгеләнгән тәртиптә кабул ителә

Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) гаризасы кергән Депутат тавыш бирүдә катнашмый.

7. Җаваплылык чарасын куллану турындагы карар гаделлек, тигезлек, пропорциональлек һәм кире кайтарылмаслык принциплары нигезендә, кылынган коррупциячел хокук бозуның характерын, аның авырлыгын, ул башкарылган шартларны исәпкә алып, шулай ук муниципаль вазыйфаны биләүче затның үз вазыйфаи бурычларын (вәкаләтләрен) гамәлгә ашыруының алдагы нәтиҗәләрен, аның тарафыннан билгеләнгән коррупциягә каршы көрәш максатларында башка чикләүләрне, тыюларны һәм бурычларны үтәвен исәпкә алып кабул ителә.

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән күрсәтелгән срокларда һәм очракларда керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен бер генә җаваплылык чарасы кулланылырга мөмкин.

8. Җаваплылык чарасын куллану турындагы карарда коррупциячел хокук бозуга күрсәтмә, муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан бозылган норматив хокукый актлар нигезләмәләре, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә карарга шикаять белдерү хокукы булырга тиеш.

9. Җаваплылык чарасын куллланудан баш тарту турындагы карарда мондый баш тартуның дәлилләнгән нигезләмәсе булырга тиеш

10. Җаваплылык чарасын куллану турындагы яисә җаваплылык чарасын куллануdан баш тарту турындагы карарның күчермәсе ул кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә муниципаль вазыйфаны биләүче затка имза салып тапшырыла яки тапшырылуы турында хәбәр белән почта аша җибәрелә, шулай ук Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) җибәрелә.

Әгәр җаваплылык чарасын куллану турындагы карарны муниципаль вазыйфаны биләүче затка җиткерү мөмкин булмаса, яисә күрсәтелгән зат имза салып карар кабул итүдән баш тартса, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары югарыда күрсәтелгән затның җаваплылык чарасын куллану турындагы, яисә мондый карар турында аңа хәбәр итү мөмкин түгеллеге турындагы карар белән таныштырудан баш тарту турында акт төзи.

11. Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын куллануdан баш тарту турындагы карарга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.